**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Ш. Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы,
Ш. Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

“28” октябрь 2015 ел. № 391

**Спорт чараларын, уку-тренировка җыеннарын һәм Татарстан Республикасының Әтнә муниципаль районында физик культура һәм спорт буенча башка чаралар үткәрүгә тотыла торган норматив чыгымнарын раслау турында**

Әтнә муниципаль районында спорт-массакүләм чараларын үткәрү өчен бюджет акчаларын рациональ һәм нәтиҗәле файдалану, шулай ук район спортчыларының һәм җыелма командаларының республика, Бөтенроссия һәм халыкара ярышларында уңышлы әзерләнүе һәм чыгыш ясавы максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 18 нче мартындагы 160 номерлы «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының спорт-сәламәтләндерү чаралары календарь планына кертелгән физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм уку-тренировка чараларын үткәрүгә тотыла торган норматив чыгымнарын раслау турында»гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Физик-сәламәтләндерү, спорт һәм уку-тренировка чаралары үткәргәндә спортчыларны, тренер-укытучыларны һәм белгечләрне тукландыруны тәэмин итү нормалары (1 нче кушымта);

Физик-сәламәтләндерү, спорт һәм уку-тренировка чаралары үткәргәндә спортчыларны, тренер-укытучыларны һәм башка катнашучыларны торак белән тәэмин итү нормалары (2 нче кушымта);

Спорт чараларын үткәргәндә спорт хөкемдарларына хезмәт күрсәтү өчен түләү нормалары (3нче кушымта);

Спорт чараларын үткәргәндә истәлекле бүләкләр сатып алу нормалары (4 нче кушымта);

Спорт чараларында катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге транспорт белән тәэмин итүгә тотыла торган чыгымнар нормалары (5 нче кушымта);

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә районы башкарма
комитеты 28.10.2025ел
№ 391 карарына

**Физик-сәламәтләндерү, спорт һәм уку-тренировка чаралары үткәргәндә спортчыларны, тренер-укытучыларны һәм белгечләрне туклландыруны тәэмин итү нормалары**

| Спорт ярышлары | Көнгә бер кешегә тотыныла торган чыгымнар нормасы, сум. |
|---|---|
| 1. Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм күнекмә-тренировка чаралары (җыеннар). | 365 кә кадәр |
| 2. Татарстан Республикасы Чемпионатлары, Первенстволары, Кубоклары һәм аларга бәйле уку-тренировка чаралары (спартакиадалар, универсиадалар) | 425 кә кадәр |
| 3. Бөтенроссия ярышлары һәм аларга әзерлек уку-тренировка чаралары | 730 кә кадәр |
| 4. . Халыкара ярышлар һәм алар өчен уку-тренировка чаралары, олимпия һәм паралимпия булмаган спорт төрләре буенча. | 785 кә кадәр |
| 5. Халыкара ярышлар һәм алар өчен уку-тренировка чаралары, олимпия һәм паралимпия спорт төрләре буенча. | 850 кә кадәр |

Искәрмә:

1. Спортчыларны, тренер-укытучыларны һәм белгечләрне физик культура-сәламәтләндерү, спорт һәм уку-тренировка чаралары үткәргәндә нормадан арткан туклану чыгымнарын каплау, оешмаларның эшчәнлек һәм башка табышлы эшчәнлекләрдән алган акчалары, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчалар хисабына башкарыла.

2. Авырлыгы 90 кг-дан артык һәм (яки) буе 190 см-дан югары булган спортчылар өчен, әлеге кушымтада каралган нормаларны аерым очракларда, бюджет акчалары чикләрендә 50 процентка кадәр арттырырга мөмкин.

3. Спорт чаралары үткәрелә торган урыннарда оештырылган туклануны түләү өчен мөмкинлекләр булмаганда, спорт чараларында катнашучыларга әлеге кушымтада китерелгән чыгым нормалары чикләрендә наличный акча бирү рөхсәт ителә.

4. Спорт чаралары үткәрелгәндә, хөкемдарларның барлык категорияләре дә туклану белән тәэмин ителми. Аларның хезмәт хакы әлеге карар белән расланган спорт чараларын башкарган өчен хөкемдарларга түләү чыгымнары нормаларына туры китереп түләнә.

5. Чаралар үткәрүче оешмалар, бюджеттан тыш, иганәчелек акчалары, шулай ук гариза бәяләре исәбеннән, барлык категория хөкемдарларына туклану өчен компенсация түләвен гамәлгә ашырырга хокуклы.

6. Спортчыларга, тренер-укытучыларга һәм белгечләргә спорт чаралары үткәрелгән вакытта туклану оештырылганда, көндәлек акчалар түләнми.

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә районы башкарма
комитеты 28.10. 2025ел
№391 карарына

**Физик-сәламәтләндерү, спорт һәм уку-тренировка чаралары үткәргәндә спортчыларны, тренер-укытучыларны һәм башка катнашучыларны торак белән тәэмин итү нормалары**

| Торак пунктлар категорияләренең атамалары | Көнгә бер кешегә тотыныла торган чыгымнар нормасы, сум. |
|---|---|
| 1. Мәскәү шәһәре, Санкт-Петербург шәһәре, Сочи | до 1120 |
| 2. Россия Федерациясе субъектларының административ үзәкләре; Ерак Төньяк территориясенә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар. | 910-1120 |
| 3. Россия Федерациясе территориясендәге башка шәһәрләр һәм торак пунктлар | 670-850 |

Искәрмә:

1.Спортчылар, тренер-укытучылар һәм башка спорт-сәламәтләндерү, спорт һәм уку-тренировка чараларында катнашучылар өчен нормадан арткан яшәү чыгымнарын каплау, оешмаларның эшчәнлек алып барудан һәм башка табышлы эшчәнлекләрдән алынган акчалар, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчалар хисабына башкарыла.

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә районы башкарма
комитеты 28.10. 2025ел
№ 391 карарына

**Спорт чараларын үткәргәндә спорт хөкемдарларына хезмәт күрсәтү өчен түләү нормалары**

| Хөкемдар | Судья категорияләрен исәпкә алып түләүләр күләме, сум. | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | МК, ВК | 1К | 2К | 3К/Ю/С | Категориясез |
| Баш хөкемдар | 745 | 630 | - | - | - |
| Баш хөкемдар, секретарь | 745 | 630 | - | - | - |
| Баш хөкемдар урынбасары, баш секретарь | 685 | 570 | 455 | - | - |
| Хөкемдарлар | 640 | 510 | 435 | 400 | 340 |
| Командалы уен спорт төрләре | | | | | |
| Уенның баш хөкемдары | 435 | 400 | - | - | - |
| Баш хөкемдарның ярдәмчесе | 365 | 340 | - | - | - |
| Инспектор (техник вәкил, комиссар) | 435 | - | - | - | - |
| Хөкемдарлар (бригада составында) | 330 | 310 | 285 | 260 | 230 |

**Шартлы билгеләр:**

- **МК** - халыкара категорияле спорт судьясы;
- **ВК** - Россия Федерациясе категорияле спорт судьясы;
- **1К** - беренче категорияле спорт судьясы;
- **2К** - икенче категорияле спорт судьясы;
- **3К** - өченче категорияле спорт судьясы;
- **Ю/С** - яшь спорт судьясы.

**Искәрмә:**

1. Түләүләр ярышның бер көне хезмәте өчен каралган, команда уен спорт төрләрендә исә түләүләр бер уен хезмәте өчен башкарыла (футбол, хоккей, баскетбол, волейбол, су полосы, гандбол, бенди, хоккей на траве, бейсбол, регби һ.б.).
2. Халыкара, бөтенроссия ярышларын, Татарстан Республикасы чемпионатлары һәм кубокларын оештыру һәм үткәрүне контрольдә тоту өчен, баш судьялар өчен каралган күләмдә түләүләр белән инспекторлар яки техник делегатлар билгеләнергә мөмкин.

4 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә районы башкарма
комитеты 28.10. 2025ел
№ 391 карарына

**Спорт чараларын үткәргәндә истәлекле бүләкләр сатып алу нормалары**

| Спорт чаралары исемнәре | Истәлекле бүләкләрнең бәясе, сум | |
|---|---|---|
| | Командалы ярышлар | Шәхси ярышлар |
| 1. Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган халыкара ярышлар | | |
| I урын | до 2000 | до 1500 |
| II урын | до 1800 | до 1300 |
| III урын | до 1600 | до 1100 |
| 2. Россия, Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре һәм кубокларының финаллары, шулай ук спорт-массакүләм чаралары: | | |
| I урын | до 1500 | до 1200 |
| II урын | до 1300 | до 1000 |
| III урын | до 1100 | до 800 |

**Искәрмә:**

1. Истәлекле бүләкләрнең бәясе күләмендә акчалата бүләкләү тыела.
2. Командалы спорт төрләрендә һәм командалы дисциплиналарда, призлы урыннарны алган командаларга кубоклар, ә команда әгъзаларына Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының медальләре һәм дипломнары тапшырыла.
3. Татарстан Республикасы кубокларында чыгыш нәтиҗәләре буенча, I урынны алган катнашучыларга яки командаларга кубок, медаль һәм диплом, ә II һәм III урыннар өчен призлы урыннарны алучыларга медальләр һәм дипломнар тапшырыла.
4. Спортчы- җиңүчеләр һәм призлы урыннарны алучыларның (командаларның) тренер-укытучыларына Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының дипломнары тапшырыла.

5 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә районы башкарма
комитеты 28.10. 2025ел
№ 391 карарына

**Спорт чараларында катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге транспорт белән тәэмин итүгә тотыла торган чыгымнар нормалары**

| №п/п | Транспорт төре | Сәгатьлек аренда бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Автобус | до 1050 |
| 1.1 | Югары уңайлылыклы автобус | до 1250 |
| 2. | Микроавтобус (9 урынга кадәр) | до 600 |
| 2.1 | Югары уңайлыклы микроавтобус (халыкара ярышлар үткәрелгәндә) | до 700 |
| 3. | Җиңел автомобиль | до 600 |
| 3.1 | "Люкс" класлы җиңел автомобиль | до 800 |
| 4. | 3,5 тоннага кадәр йөк күтәрә ала торган йөк автомобиле | до 650 |
| 4.1 | 3,5 тоннадан югары йөк күтәрә ала торган йөк автомобиле | до 900 |
| 5 | "Ашыгыч ярдәм" машинасы | до 2500 |

**Искәрмә:**

1. Спорт көймәләрен, яхталарны, атларны ташу өчен махсус автоконструкцияләргә түләү, законнарда каралган тәртиптә, оешмалар белән төзелгән килешүләр буенча башкарыла.
2. Автотранспортны арендалау гадәти ярышлар өчен көнгә 10 сәгатьтән, халыкара ярышлар өчен көнгә 12 сәгатьтән артмаска тиеш.